СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.06.2020 № 41/5

На № __________ от ________________

# КАРАР

**«2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасының үтәлеше турында**

«2015-2020 елларга Тукай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасының үтәлеше турында мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Район Башкарма комитетына:

- коррупция һәм башка хокук бозулар предметына гражданнар мөрәҗәгатьләренә, Совет һәм район Башкарма комитеты хезмәткәрләрендә мәнфәгатьләр конфликтына, хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын бозуга китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык булу мөмкинлегенә көн саен анализ ясарга;
- «Тукай муниципаль районы капиталь төзелеш хезмәте» МУП, «Тукай муниципаль районы контроль-хисап палатасы» МКУ, район Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге белән берлектә, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан төзекләндерелгән социаль инфраструктура һәм күп фатирлы йортлар объектларын капиталь төзекләндерү сыйфаты буенча тикшерү алып барырга. Сыйфатсыз башкарылган эшләр буенча аларны бетерү буенча чаралар күрергә.

3. Район финанс-бюджет палатасына:

- җирле бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалануны контрольдә тотуны оештырырга;
- эчке стандартларны һәм процедураларны үтәүгә юнәлдерелгән эчке контрольнең сыйфатын һәм ышанычлылыгын арттыру буенча, бюджетны төзүне һәм үтәүне, бюджет исәбен алып баруны, бюджет хисаплылыгын төзүне, административ регламентларны үтәүне, шулай ук бюджет акчаларыннан

файдалануның нәтиҗәлелеген (нәтиҗәлелеген һәм экономлылыгын) арттыруга юнәлдерелгән чараларны әзерләү һәм гамәлгә ашыруны оештыруны да кертеп, чаралар күрергә.

4. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына милек белән идарә итү, файдалану һәм эш итү тәртибен җайга салучы гамәлдәге законнарны бозу фактларын ачыклау һәм мондый хокук бозуларга юл куйган затларны билгеләү буенча даими эш алып барырга.

5. Районның җирле үзидарә органнарына, аларның структур бүлекчәләренә, оешмаларга һәм учреждениеләргә:

- Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе карарларын һәм Тукай муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе карарларын үз вакытында үтәүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Р.И. Закиров